ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» 01 2020 г. № 11

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Яңгул авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча гавами (ачык) тыңлаулар үткәрү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24, 28 статьялары, Балтач муниципаль районы Уставының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2007 елның 24 мартындагы 66 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гавами тыңлаулар үткәрү турында» Нигезләмә нигездә, кешенең тормыш эшчәнлегенең уңай шартларына хокукларын, «Яңгул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында Балтач муниципаль районы башлыгы карар бирә:

1. Яңгул авыл җирлеге халкы катнашында «Яңгул авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Яңгул авылы гражданнары өчен «Яңгул авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлауларны 2020 елның 15 февралендә 11:30 сәгатьтән 12:00 сәгатькә кадәр Яңгул мәдәният йортында түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Балтач районы, Яңгул авылы, Дуслык урамы, 1 нче йорт.

3. Иске Көшкәт авылы гражданнары өчен «Яңгул авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлауларны 2020 елның 15 февралендә 12:30 сәгатьтән 13:00 сәгатькә кадәр Иске Көшкәт авыл клубында түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Балтач районы, Иске Көшкәт авылы, Дуслык урамы, 18а нчы йорт.

4. Балтач муниципаль районының «Яңгул авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең территорияне территориаль планлаштыруның шәһәр төзелеше документларын әзерләү буенча комиссиясенә (алга таба - Комиссия) гавами тыңлаулар үткәрүне оештырырга.

5. Комиссиягә «Яңгул авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы буенча демонстрацион материаллардан күргәзмә-

экспозицияләр оештырырга, гавами тыңлаулар тәмамланганнан соң, тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә.

6. Генераль план проекты буенча гражданнардан тәкъдимнәр әлеге карар басылып чыкканнан соң бер ай эчендә Яңгул авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Балтач районы, Яңгул авылы, Дуслык урамы, 2 нче йорт.

7. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatar.ru рәсми сайтында һәм Яңгул авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Балтач
муниципаль районы башлыгы Р. Р. Нотфуллин